**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________ № ______

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 мартындагы ПР-57 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районының мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификацион төркеменең мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлек хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 22 августындагы под-1344/25 номерлы «Муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге) муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Типовой нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» боерыгы Татарстан Республикасы «атамасы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының, муниципаль берәмлекләрнең мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгы белән расланган, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы 583/22 номерлы боерыгы белән расланган, муниципаль берәмлек педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы «атамасы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты составындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Типовой нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 1 пункты түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп оклады түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.М. Шакировага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш. Бариев

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
__________ №____ карарына
кушымта

1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп оклады түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестация не уңышлы узган затка "бакалавр" ,"магистр" "яисә "дипломлы белгеч" квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт | - | - | 24598,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары; | | | |
| | Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы); | - | - | 24690,0.». |